**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЕГЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**14 нче ноябрь 2016 ел** **№ 69**

Акъегет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә 2017 елның 1 гыйнварыннан җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында

Акъегет авыл җирлеге башлыгы Шәмсиев Сәлимҗан РИФКАТ улының 2016 елның 1 гыйнварыннан җир салымын түләү ставкаларын, тәртибе һәм сроклары турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Акъегет авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ.:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Акъегет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә 2017 елның 1 гыйнварыннан әлеге территориядә мәҗбүри булган җир салымын (алга таба - салым), түбәндәге күләмнәрдә салым ставкаларын билгеләп, гамәлгә кертергә:

1.1) 0,2% торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына караучы объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокукындагы өлештән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата;

1.2) 0,2% шәхси ярдәмче хуҗалык өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата,

1.3) 0,3% бакчачылык, яшелчәчелек яки терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата;

1.4) 0,3% авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә җирлек торак пунктларында авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата;

1.5) 0,3% Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборонаны, куркынычсызлыкны һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата;

1.6) 0,403% Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр биләгән торак пункт җирләре категориясенә керә торган җир кишәрлекләренә карата;;

1.7) 0,403% казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр биләгән, җирле бюджеттан финанслана торган торак пунктларның җирләре категориясенә керә торган җир кишәрлекләренә карата;;

1.8) 1,5% сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары җирләренә карата;

1.9) 1,5% башка җир кишәрлекләренә карата.

2. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен законнар белән каралган салым түләүчеләрдән тыш, җир салымын түләүдән азат итү:

- Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары.

-гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата оешмалар, учреждениеләр;

-муниципаль казна учреждениеләре авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә, су башнялары, скважиналар, канализация-насос станцияләре, чистарту корылмалары, каты көнкүреш калдыклары полигоннарына, үләт базлары, автомобиль юллары, скверлар, парклар, мәйданнар, һәйкәлләр, обелисклар белән бәйле.

3. Билгеләү:

-салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы таныла.;

- салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче квартал тәмамланганнан соң, узган хисап чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

4. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча.

5. Акъегет авыл җирлеге Советының «Акъегет авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 1 гыйнварыннан җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында»гы 2015 елның 17 ноябрендәге 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны 2016 елның 1 декабренә кадәр «Яшел Үзән» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга. http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.)

**Акъегет авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.Р.Шәмсиев**